Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ

12+

№35 (128)

11 декабрь 2014 ел



# Милли байлык – милли саулык

Влад Михневский фотолары

Һәрбер халыкның гасырларга сузылган тарихында тупланган тәпле тәҗрибәсе, матур гореф-гадәтләре, бай тәрбия зиннәтләре бар. Милли тәрбиядән башка рухи хәзинәнең, рухи хәзинәдән башка халыкның киләчәге юк. Моны истә тотып, КФУда инде бишенче мәртәбә халыклар иҗаты Идел буе яшьләр фестивале уздырыла. Төрле милләт һәм дин вәкилләре булган яшьләрдә үзара толерантлык һәм хөрмәт тәрбияләүгә юнәлтелгән әлеге чара студентларда туган илгә, халыкларның үзенчәлекле һәм кабатланмас мәдәниятенә, гореф-гадәтләренә мәхәббәт тәрбияләүдә зур эш башкара.







• Юбилей

# 210 еллык тарих – якты киләчәк!

6 декабрь көнне яраткан университетыбыз 210 еллык юбилеен каршылады. Туган көн тантанасы зурлап Татнефть-Арена Боз сараенда уздырылды. Әлеге гаҗәеп чарада КФУның 5 меңнән артык студенты, хезмәткәре һәм дәрәҗәле кунаклар катнашты.

Тантана «Gaudeamus» студентлар гимны белән ачылды. Университетны котларга ТР Президенты Р.Миңнеханов та килгән иде. «КФУны дөньяның иң яхшы 100 вузы рәтенә кертү – максатларыбызның берсе. Миңа калса, бу реаль. КФУның зур потенциалы әлеге максатларны тормышка ашырырга мөмкинлек бирә. Ә сез – республикабыздагы иң яхшы кадрлар», – диде Президент, студентлар һәм укытучы-галимнәргә мөрәҗәгать итеп.

Дәрәҗәле кунаклар арасында Казан университетын тәмамлаган студент, Россиянең Элемтә һәм гаммәви коммуникация министры Н.Никифоров та бар иде. Ул яраткан университетын бәйрәме белән котлап, бүген аның заманчалашуы турында искәртеп узды. «Шулай да югары уку йортлары үз тарихын гасырлар белән саный. Без бүген КФУның 210 еллыгын бәйрәм итәбез. Димәк, аңа 21 дистә. Шушы вакыт эчендә университет һәм аның исеме Казан тарихында лаеклы урын тотты», – дип билгеләп узды министр.

КФУ ректоры И.Гафуров вузның үсеш-үзгәрешенә бәяләп бетергесез өлеш керткәннәре өчен университет хезмәткәрләренә рәхмәт сүзләрен җиткерде. «Безнең бөек тарихыбыз, фундаментыбыз, зур потенциалыбыз бар. Бу исә, якты һәм әйбәт киләчәк дигән сүз!» – дип белдерде ул.

Бәйрәм концерты кысаларында дәүләт бүләкләре тапшырылды. Ирешелгән уңышлары булган һәм күп еллар дәвамында тырышып эшләүче университет хезмәткәрләренә РФ Президенты Рәхмәте белдерелде. ТР Президенты указы буенча, югары квалификацияле кадрлар әзерләүгә зур өлеш керткәннәре, фәнни-тикшеренү эшчәнлегендә күрсәткән хезмәтләре өчен университетның кайбер хезмәткәрләре «Данлы хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде. Шулай ук Татарстан Президентының Рәхмәт хатлары да тапшырылды.

Бәйрәм кичәсенең сценарие Казан университеты тарихына сәяхәт рәвешендә уйланылган иде. Тамашачылар XIX гасыр башы чорларына «кайтып килде», университетка нигез салу турындагы документка кул кую күренешенең «шаһитлары» булды.

Тамашаның иң истә калган мизгелләренең берсе В.Ленинның университетта укыган чорын гәүдәләндергән заманча бию булды. Пролетариат юлбашчысы сәхнәдә брейк-данс башкарды. Шулай ук корабль, байкерлар парады, квадроциклларда трюклар һәм КФУның ике биек бинасын тамашачыларның күз алдында «төзү» чын мәгънәсендә кабатланмас күренеш булды.

В.Цой музыкасына салып, үзгәртеп кору һәм яңа заман кадрларын күрсәткәндә, бөтен зал, тыелып тора алмыйча, кушылып җырлады.

Мондый зур чарада Бөек Ватан сугышында һәлак булучыларны да игътибарсыз калдырмадылар. Аларны бер минутлык тынлык, ә ветераннарны исә алкышлар белән хөрмәтләделәр.

Казан университетына «Евровидение – 2013»тә Россияне тәкъдим итүче, ТРның атказанган артисты, КФУны тәмамлаган Динә Гарипова музыкаль бүләген тапшырды.



КФУга быел 210 яшь, ә мин үзем 21 ел аның белән элемтәдә торам. Берлинда яшәүче бер алманның ничек Татарстанның башкаласындагы университет белән бәйле, дигән соравына җиңел генә бер җавап бар: һәрвакыттагыча бу юлы да очраклылык зур роль уйнады.

# КФУ һәм МИН!

**Себастьян ЦВИКЛИНСКИ,** фәлсәфә фәннәре докторы, Берлин әдәбият һәм мәдәниятләр институтының штаттагы хезмәткәре

Вакыйга 90нчы елларның башында Берлин Азат Университеты тюркология институты доценты Маргарете Әрсән-Раш белән бәйле. Дистә еллар буена төрле университетларда төрек телен укыткан Маргарете апа 90ынчы еллар башында бер конференциядә КФУ профессорлары Миркасыйм Госманов һәм Флера Сафиуллина белән танышканнан соң, бик тиз татарчага өйрәнеп, Берлин Азат Университетында башкортча һәм татарча укыта башлады. 1993нче елда Флера Сафиуллина татар телен укытырга Берлинга чакырыла. Университетның тюркология бүлегендә укучы һәр студент әлеге курсларга йөри. Мин бу вакытта тюркология бүлеге студенты булмасам да, катнашырга уйладым. Флера апаның җанлы дәресләре миндә тирән тәэсир калдырды, шунлыктан мин дә тюркология бүлегенә күчергә карар кылдым. Аннан соңгы елларда институтның Татарстан белән элемтәләре бик ныгыды: Казан университетыннан еш кына кунаклар килә башлады. Тәлгать Галиуллин, Миркасыйм Госманов, Флера Сафиуллина, Әлфия Юсупова кебек танылган татар галимнәре институтыбызда дәресләр биреп, чыгычшлар ясап, алман һәм төрек студентларына татарлар тормышы белән таныштырдылар.

Шул елларда алман студентлары Идел-Урал төбәкләренә килеп, башкортлар турында магистрлык диссертацияләре өчен материал туплый башладылар, ә мин үзем 1994нче елда башкортча һәм татарча өйрәнү өчен, Башкортостан һәм Татарстанга килдем. Флера апа безне ачык йөз белән каршы алып, бик күп мәсьәләләрне хәл итәргә булышты.Шунда мин башка галимнәр белән дә таныштым һәм татарлар тормышы белән ныклап кызысына башладым.

Тагын бер очраклы хәл: Берлиндагы бер ярминкәдә Мәскәүле татар тарихчысы Габдулхан Әхтәмҗан белән таныштым. Ул миңа яңа һәм бик кызыклы гына тема тәкъдим итте: «Икенче бөтендөнья сугышы вакытында Германия гаскәрендәге Идел-Урал легионы». Легионның 1942-1945нче елларда газета һәм журналларын тикшереп, легионның пропаганда үзәгенә анализ ясарга тырыштым. Шул ук тема белән КФУ профессоры Искәндәр Гыйләҗев та шөгыльләнгәне билгеле булгач, тагын КФУ белән элемтәгә кердем.

2003нче елда миңа тагын Казанга килергә туры килде, чөнки докторлык диссертациям өчен материал тупларга кирәк иде. Бер айга Татарстанның башкаласында калдым, тагын Казан университеты хезмәткәрләре ярдәм иттеләр. Алмания, Төркия, Казан, Уфа, Мәскәү һәм Петербургта туплаган материал буенча докторлык диссертациямне яклаганнан соң да Казанга белән элемтәм өзелми. Еш кына биредә үткәрелгән конференцияләрдә катнашам. КФУда гына 4 тапкыр катнаштым инде.

Казан университеты бик күп чит ил галимнәре белән хезмәттәшлек итә. Безнең өчен дә, үзе өчен дә зур мөмкинлекләр ача. КФУ алга таба да шулай дәвам итсә, киләчәге якты булыр!

• Аталар сүзе - акылның үзе

3 декабрь көнне Г.Тукай ис. татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлегенең икенче-дүртенче курс студентларының филология фәннәре кандидаты Луиза Фирдүс кызы Җамалиева җитәкчелегендә «Халык энҗеләре җыйганда» дип аталган фольклор практикасы конференциясе узды.

# Халык энҗеләре тупланды

**Йолдыз ХӨРМӘТУЛЛИНА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты







Чара җәйге фольклор практикасына нәтиҗә ясау буларак үткәрелде. Шунысы игътибарга лаек: фольклор практикасын узу географиясе шактый киң: җөмһүриятебезнең 28 районын, Чувашиянең 3 районын, Башкортстанның 1 районын һәм Үзбәкстанның Ташкент каласын да колачлады. Нәтиҗәдә, практика вакытында татар халкының гына түгел, ә чуваш, үзбәк халкының һәм керәшеннәрнең йола һәм календарь бәйрәмнәрен үткәрү, үзенчәлекләре, җырлары-бәетләре тупланды.

Фольклор практикасын үткән 71 студентның эшләрен анализлап, гомуми тикшеренүләр тәмамлангач, кызыклы һәм файдалы мәгълүматларны киңрәк тарату һәм бу гаять әһәмиятле гамәли курска йомгак ясау максаты белән уздырылды конференция. Чыгышлар гаять кызыклы булды: татар халкының үз йолалары – Карга боткасы, Күкәй җыю бәйрәме, Каз өмәсе турында да сөйләделәр. Татар зиратындагы Ишан хәзрәт каберлеге, үзбәкләрнең һәм чувашларның туй йолалары, бәетләр һәм җырлар хакындагы мәгълүматлар студентлар өчен дә, чарага килүче башка кунаклар өчен дә бик файдалы булды. Конференция барышында башкарылган халык җыры «Ашхабад» һәм мөнәҗәтләр чарага миллилек өстәделәр. Практика үткән вакытта авыл-шәһәрләрдә юлыккан кызыклы вакыйгаларны КВН рәвешендә күрсәтеп киттеләр. Бу – практиканың иң күңелле, иң истә калырлык вакыйгаларын искә төшереп, йөзләргә елмаю, шатлык өстәде. Болардан тыш, студентларның үз куллары белән чиккән кулъяулыклары, теккән алъяпкычлары, шәл-яулыклары, өстәл япмалары да күргәзмәгә куелды. Луиза Фирдүс кызы: «Бер кызга бирнә итеп биреп җибәрергә җитә инде болар», – дип шаяртты. Һәр шаяруда хаклык бар, диләр. Чыннан да, кызларга мондый кул эшләре күргәзмәсе бик файдалы булгандыр, дип уйлыйм.

Чараны оештыручы, фольклор практикасы курсы җитәкчесе Луиза Фирдүс кызы конференциянең әһәмияте, үзенчәлекләре хакында сөйләп, җыелган эшләргә йомгак ясады. Остазыбызга әлеге зур хезмәте өчен зур рәхмәт. Шушы фольклор практикасы аша безгә киләчәккәяңаюлларкүрсәтелде,яңа юнәлешләр ачылды. Монда татар халкының үз рухи байлыгына җылы мөнәсәбәте дә, җырларындагы моңнар да, йола үзенчәлекләре дә, миллилеге дә бар иде! Практика үтү чорында һәм конференциядә алган белемнәребез безне рухи яктан гына баетып калмыйча, татар милләтенә дә файда китерер, киләчәктә дә камилләшер дигән өметтә калабыз.

**• Ерактагы якын кардәшләр**



*«Исәнмесез, хөрмәтле «Дарелфөнүн» газетасы хезмәткәрләре, яраткан укытучыларыбыз, кадерле дуслар, туган уку йортыбыз! Сезгә Төркиядән кайнар сәлам! Сезгә Г. Тукай ис. татар филологиясе бүлеге студенты Альбина Вәлиева яза...*





# Туган тел – халык җаны...

Бер ел элек үз теләгем белән төрек теле курсларына йөри башладым. Укытучыбыз Элмира апаның «Төркиядә Искешәһәр дип аталган татарлар шәһәре бар», дигән сүзләре хәтеремә бик яхшы кереп калган. Әмма үземә шул шәһәрдә укырга, күпмедер вакыт яшәргә насыйп булыр дип күз алдыма да китермәгән идем.

Татар филологиясе бүлегеннән безне Төркиянең Искешәһәренә бер семестрга укырга җибәрделәр. Истанбулдан автобуста Искешәһәргә барганда, без Кырым татарлары белән таныштык. Алар, безнең татарча сөйләшкәнне ишеткәч, яныбызга килделәр. Чит илдә туган телемне аңлаган кешеләр очратканыма бик гаҗәпләндем. Автобуста без Казаннан 4 кеше идек. Алар, безнең Казаннан килүче студентлар икәнебезне белгәч, Искешәһәр татарлары җәмгыяте җитәкчесе Фәрхәт абый Акташка шалтыраттылар һәм шул ук көнне Фәрхәт абый дусты Ихсан Таңатар белән безне автовокзалда каршы алды. Туган шәһәренә үзенең милләттәшләре килүенә бик шатланды. Без татарлар белән аралашуга бик тансык, ди ул. Сөйләме урыны белән төрек теленә охшаш булса да, туган телен барыбер онытмаган. Бераздан ул безгә мисафирханәгә урнашырга ярдәм итте, шәһәрне күрсәтте. Бер атна үткәч, без Искешәһәрдәге Казан татарлары музеена киттек. Бу музейны Фәрхәт абый һәм татар җәмгыяте рәисе Нади Өздамар җитәкли. Форсаттан файдаланып, Фәрхәт абыйга берничә сорау бирдем:

**- Фәрхәт абый, сезнең ата-бабаларыгыз ничәнче елда Төркиягә күчеп килгән?**

- 1890-1895нче еллар арасында Хаҗи Нәгыйн Йафай исемле кеше Ырымбурдагы Зубачи авылыннан һәм әбием Зәйтүнә Чирмешән районы Кармыш авылыннан 8-9 яшендә бертуган апасы Шәмсия белән Төркиягә күчеп килгәннәр.

**- Татар телен ничек өйрәндегез?**

- Без Төркиянең Османие авылында үстек. Мәктәпкә укырга кергәнче, төрекчә белми дә идек. Өйдә һәрвакыт татарча сөйләштек. 90нчы еллардан соң, Татарстанның Саба районы Шәмәрдән авылыннан Искешәһәргә Анадолу университетына студентлар килде. Алар бездә бер елдан артык укып киттеләр. Алар белән аралашып, без татар телебезне ныгыттык, язарга, укырга өйрәндек.

**- Туган авылыгыз Искешәһәрдән еракмы? Анда еш кайтасызмы?**

- Османие авылы Искешәһәрдән 80-90 километр ераклыкта урнашкан. Туган авыл бик сагындыра, әмма соңгы арада бик еш кайта алмыйбыз, туып-үскән йортыбыз күптән юк инде, туганнарыбыз да калмаган.

**- Искешәһәрдә Казан татарлары музее кайчан ачылды? Аның ачылуына нәрсә этәргеч булды?**

- Без Татарстан Президентына, мәдәният министрына, татар конгрессына бик күп хатлар яздык. Искешәһәргә килүче татарларны кунак итәр өчен, мәдәни йорт сорадык һәм 2012 елда шәһәребездә Казан татарлары музее ачылды. Шулай ук 1992 елдан башлап, Искешәһәрдә Казан татарлары җәмгыяте эшләп килә.

**- Искешәһәрдә барлыгы күпме татар яши? Сез берберегез белән элемтәдә торасызмы?**

- Искешәһәрдә 150 меңгә якын татар яши, Казан татарлары 1500 кешегә якын. Бер-беребез белән күбрәк бәйрәмнәрдә, төрле чараларда аралашабыз. Туган авылым Османиеда бик еш Сабантуй бәйрәмен үткәрәбез, шунда көрәшәбез. 2013 елда Искешәһәр төрки дөньяның мәдәни башкаласы дип игълан ителде. Бу сәбәпле бездә бик зур Сабантуй бәйрәме үткәрелде. Татарстан Республикасы Президенты һәм башка мәртәбәле шәхесләр безгә кунакка килде. Татарстанның танылган ансамбльләре чыгыш ясады. Бу бәйрәм безнең дуслык мөнәсәбәтләрен тагын да ныгытты, бик күп кешеләр белән таныштык.

**- Яшьләр арасында татар телен камил белүчеләр бармы?**

- Кызганычка каршы, бик аз. Без үзебезне соңгы нәсел дип саныйбыз. Әмма өйрәнергә тырышучылар бар, Искешәһәрдә хәтта татар теле курслары да ачылган иде. Кайберәүләр туган телебезне Казанга китеп өйрәнә.

**- Өйдәгеләр белән нинди телдә аралашасыз?**

- Өйдәгеләр белән һәрвакыт татарча сөйләшәбез. Балаларыбызның Татарстанда дуслары бик күп, алар белән интернетта татарча аралашырга тырышалар.

**- Казанда еш буласызмы? Шәһәребезне яраттыгызмы?**

- Беренче тапкыр Казанда 1995 елда булдым. Әлмәт, Яр Чаллы, Саба якларында булып кайттык. 2012 елда Бөтендөнья татар конгрессына бардым. Ул елны әбибабайларның туган җире - Кармыш авылына да барып кайттык, туганнарда кунак булдык. Алар да бераздан Искешәһәргә Сабантуйга килделәр. Казан шәһәре миңа бик ошады, тагын бер барып кайтыр идем.

**- Фәрхәт абый, бүгенге татар яшьләренә нинди киңәшләр бирер идегез?**

- Бүгенге татар яшьләренә киңәшләрем шул: үзләренең туган телен, гореф-гадәтләрен һәм кем икәннәрен, ягъни татар булуларын онытмасыннар, үз милләте белән горурлансыннар.

# Ана теле сакчысы

**10.2-203, 10.2-204 төркем студентлары,**
Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

Милләт җанлы, тирән белемле, татар рухлы, нык эрудицияле, туган илгә хезмәт итүне иң изге бурычлардан саный торган, үзләренең гомерен, талантын шул эшкә багышлаучы галим-галимәләр, шагыйрь-шагыйрәләр XIX-XX гасырларда гына яшәп иҗат иткәннәр дисәк, дөрес булмас.



Борын заманнардан ук бөтен яктан да үзәк булган Казаныбызда телне үстерү өлкәсендә зур эш алып барылган, хәзерге көндә дә уку йортыбыз бу эшне нәтиҗәле дәвам итә. Күптән түгел Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында узган «Телләрне һәм мәдәниятләрне саклау һәм үстерү» III Халыкара фәнни-гамәли форумына җир шарының төрле почмакларыннан кунаклар килде.

Аеруча ерак араны якын итеп килгән Финляндия кунагын – Кадрия апаны билгеләп үтәсебез килә. Төрек дөньясының таҗы булган Казаннан ерак торуына карамастан, әби-бабаларыбыздан килгән гореф-гадәтләрне саклап, үстереп, хәзерге буынга тапшыру вазифасын башкаруда зур эш алып баручы, татар милләте өчен җан атучы кунагыбыз белән III курс студентларының диалектология дәресе кысаларында күңелле очрашу булып узды.

Кыска гына вакыт аралыгында Кадрия апа Финляндия татарларының көнкүрешен, милләтебезне саклау, барлау өстендә эш алып барулары турында сөйләде. Аеруча да кунагыбызның саф татар телендә сөйләшүе безне таң калдырды. Чит илдә үсеп, башка милләт вәкилләре даирәсендә яшәп, туган телен саклап калуының сере нидә икән? Кадрия апа әйтүенчә, гаиләдәге тәрбия һәм үзара мөнәсәбәтләр аның ачкычы булып тора. Балачактан ук гаиләдә татар телендә генә аралашкан кунагыбыз әтиәнисенең үз сүзләрендә нык торуларына, татарлыкларыннан оялмауларына, таләпчән булуларына бүгенге көнгә кадәр рәхмәтле. Әмма бу сернең икенче ачкычын да күздә тотарга кирәк. Кадрия апа халкының тарихы, килеп чыгышы белән нык кызыксына һәм бабаларының чыгышлары буенча Нижгар губернасының Сергач өязеннән сәүдәгәрләр булганлыгын ачыклый. Алар 1870-1920 елларда төрле сәяси сәбәпләр аркасында Финляндиядә төпләнеп калган.

*Аппак алтын җырларымны*
*Җырламыйм данлык өчен,*
*Җырлаем алтын илем чөн,*
*Үз туган халкым өчен.*
***С.Рәмиев***

Бүгенге көндә фин илендә булган татарларның саны 1000гә җитә. Аларның күбесе Хельсинки, Турку һәм Тампере шәһәрләрендә яшиләр икән. Сан ягыннан бик үк күп булмасалар да, аларның милләт өчен эшләгән эшләре санап бетергесез. Финляндия татарлары телне, гореф-гадәтләрне, милли бәйрәмнәрне, динне югалтмас өчен тырышалар. Кадрия апа сөйләве буенча, милли йолалар, гореф-гадәтләр һәм төрле милли чаралар әлегә кадәр сакланып килә.

Шунысы ачык билгеле: милләт җанлы кешеләр XXI гасырда да бар, ә алар булганда, милләт тә, тел дә яшәячәк!!!

**• Халык җәүһәрләре**

Уку йортыбызда 7-10 декабрь көнннәрендә «Милли хәзинә» дип исемләнгән Идел буе уку йортларында укучы студентлар фестивале булып узды.

# Милли байлык – милли саулык

**Йолдыз ХӨРМӘТУЛЛИНА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты



Влад Михневский фотолары

Бу фестиваль быел дүртенче тапкыр гына үткәрелсә дә, аның даны Идел буе төбәкләренең төрле почмакларына таралаган. Оренбург, Санкт-Петербург кебек шәһәрләрдән, Дагестан, Мордовия, Чувашия Республикаларыннан, Киров өлкәсеннән, Татарстан Республикасының Чистай, Тәтеш, Минзәлә, Балык Бистәсе районнарыннан, Алабуга, Казан шәһәрләреннән студентлар катнашты бу чарада. Быел фестивальнең географиясе дә киңрәк булды, яңа номинацияләр дә бар иде.

Фестивальгә кунаклар, катнашучылар 6нчы декабрь көнне үк килә башладылар. Һәр делегациягә икешәр волонтер беркетелгән иде. Мин дә, дустым Элиза белән бу күңелле вакыйдан читтә калмас өчен, Киров өлкәсе делегациясенә волонтер буларак язылдык. Безнең «кул астыбыздагы» делегациядә нибары ике кыз иде: Нократ дәүләт университетының 3нче курс студентлары Алена һәм Елена. Кызлар, монда килгәнче үк, Казан турында укып, ишетеп белгәннәр икән. Шәһәр белән таныштыруны да без данлыклы Бауман урамыннан башладык. Моннан тыш, яңа төзелгән «Казан-Арена» футбол стадионы, «Ривьера» аквапаркы һәм Казан гаилә үзәге дә кызларда уңай тәэсир калдырган.

8нче декабрь көнне сайлап алу туры уздырылды. Төрледән-төрле жанрлар, костюмнар, кул эшләре... Искиткеч төрлелек, искиткеч миллилек! Яңа идеяләр, үзгәрешләр, югары зәвыклылык, нәфислек... Аеруча, мордва һәм татар мәдәниятенә хас үзенчәлекләр күңелдә уелып калды.

Катнашучылар иртәнге якта сәхнәдә балкысалар, кичен Казан шәһәренең «балкуын» карап йөрделәр. «Милли хәзинә» кунаклары күңеленә «Кичке утлар» экскурсиясе хуш килгәндер, шәт!

9нчы декабрь көнне исә, сайлап алу турыннан узып, төрле дәрәҗәдәге урыннар яулаган катнашучыларны бүләкләү тантансы – гала-концерт булды. Сәхнәдәге җем-җем утлар, чыгыш ясаучыларның әзерлеге, кабатланмас чыгышлары чараны тагын да бизәде. Урыннарга лаек булучылар бик күп иде: безнең яңа дусларыбыз – Алена белән Елена III дәрәҗә диплом белән бүләкләнделәр. Шунысы сөендерә: безнең университетыбыз, институтыбыз студентлары да бу чарада бик теләп катнаштылар. Бүлегебез студентлары Айгөл Галәветдинова һәм Ленар Хамматов «Әлдермештән Әлмәндәр» пьесасыннан өзек белән Іурын, Эльвина Нәҗипова нәфиссүз номинациясендә, «Мизгел» яшьләр театры театр номинациясендә, «Раушан» төркеме нәфис сүз юнәлешендә, «Яшьлек» бию төркеме хореография юнәлешендә II урын яулаулары белән безне сөендерделәр, шул ук вакытта таң калдырдылар! Гран-прига лаек дип табылган Яковлев исемендәге Чуваш дәүләт педагогика университеты студентлары башкарган эшләр, җыр-биюләре чын дәрәҗәдә милли ачыш, милли хәзинә иде. Фестиваль һәркемнең дә күңеленә хуш килгәндер дип уйлыйм. Катнашкан студентлар, оештыручылар диплом-кубоклар белән генә түгел, ә яңа дуслар, яңа идеяләр, яна кичерешләр белән дә баеганнар дигән өметтә калам. Милли хәзинәбез елдан-ел баесын, үз кыйммәтен төшермәсен иде!

**• Студент тормышы**

# Без кино да төшерәбез!

**Гөлфиназ НӘБИУЛЛИНА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

Син кино карарга яратасыңмы яисә үзеңнең фильм төшерәсең киләме? Алайса, дустым, «Киномания» конкурсы нәкъ менә синең өчен!



Әдөньяда иң беренче «Ля-сиото вокзалына поезд килүе» дип аталган фильм 1895 елда барлыкка килә. Чара башында без шул фильмны карадык. Хәзерге кинолар да кешеләргә тәэсир итмичә калмыйлар. Алар уйландыра да, көлдерә дә, елата да. Кино – ул хәзерге дөньяның чагылышы, яшәешнең көзгесе. Һәр елны Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты тарафыннан оештырыла торган бу чарада быел 25 кыска метражлы фильм тәкъдим ителде. Монда барлык теләгән кешеләр төрле жанрларга караган үз видеоязмалары белән катнаша ала. Бәйгедә җиңүчеләр «Студент тормышы», «Студент күзлегеннән Казан», репортаж, кыска метражлы фильм, социаль ролик, артвидео, видеоклип, кызыклы видео тематикасы һәм жанр юнәлешләре буенча бүләкләнде.

Студентларны нәрсә кызыксындыра һәм борчый соң? Монда мәхәббәт, көлке-юмор, аш-су да үз урынын тапкан. Студентлар үзләрен режиссер, оператор, сценарист буларак сынап карый ала. Кем белә, бәлки, араларында нәкъ шул һөнәр буенча белгечләр үсеп чыгар?! Бу бәйге – һәр кешегә иҗади яктан үсү өчен бик зур мөмкинлек.

Видеоязмаларның иң-иңнәрен тантанада тамашачыларга күрә алу бәхете елмайды. Иң яхшы фильмнар тамашачылар белән берлектә бәяләнде. Бүләкләү өчен мәртәбәле жюри әгъзаларын чакырдылар, алар үзләренең шаярулары белән тамашаны тагын да җанландырып җибәрделәр һәм кайбер хаталарны да кисәтеп киттеләр.

Чара бик тиз узып та китте, ләкин күңелдә бер елга җитәрлек хис-кичерешләр калды!

**• Халәт**

Соңгы берничә айда нинди генә газета битләрен, телевизион каналны ачып карама, һаман бер сүзне кабатлыйлар – нефть бәясе төшә, сумның долларга карата курсы түбәнәя.

# Уяныйк, Кешеләр, уйланыйк!

**Галия СӘЛИМОВА**

Илебездә бюджет күлмәген нефть бәясенә карап кисkәнгә күрә, телибезме без, юкмы, бәяләр өскә үрмәли, хезмәт хакларының чит ил валютасындагы күләме кечерәя. Бу, үз чиратында, яңа финанс кризисының якынлашуы турында искәртә. Шул «афәт» аркасында күпләр инде төшенкелеккә дә бирелә башлады.

Әлбәттә, акча кризисы – начар күренеш. Әмма соңгы вакытларда шуның күләгәсендә калган рухи-әхлакый кризис турында бөтенләй үк онытып барабыз түгелме? Әйтерсең, бар дөньясы шул акчага гына корылган. Хәер, бүген шулай дип санаучылар да юк түгелдер.

Яшьләрнең тәмәке тарту, эчкечелек, наркомания кебек бозык күренешләр белән мавыгуына, туган телебезне онытa баруыбызга, чит-ят сүзләр кыстырып сөйләшүебезгә дә күптән гаҗәпләнмибез инде. Ә Табигать-анабызга гамьсез, саксыз карашны, әхлакый түбәнлек димичә, тагын ничек атап була? Күңелебез көннән-көн катылана, рухыбыз зәгыйфьләнә, әхлагыбыз түбәнәя баруын сизмибез дә, күрмибез дә. Миңа калса, хәзерге заманда җәмгыятебезне шушы хәлгә җиткергән әхлаксызлык күренешләре турыдан-туры тәрбия мәсьәләсенә бәйле. Халкыбызда «Оясында ни булса, очканында шул була» дигән әйтем яши. «Алма агачыннан ерак төшми» дигәне дә бар. Әлеге гыйбарәләр борын-борыннан ук гаилә тәрбиясенең ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуы турында искәртә. Ә без бүген гаилә тәрбиясе хакында бик сирәк искә алабыз, гаилә институтын ныгыту өчен тиешле дәрәҗәдә дәүләти чаралар да күрелми. Аерылышулар саны көннән-көн арта. Рәсми җыелышларда, хөкүмәт утырышларында, илкүләм форумнарда, гадәттә, сүз бары тик икътисад, сәясәт, житештерү хакында гына бара. Дөрес, сыйфатлы азык-төлек, кием-салым һәм башка төрле матди кирәк-ярак эшләп чыгару –мөһим әйбер. Шулай да теләсә кайсы дәүләтнең иң төп эше һәр яктан камиллеккә омтылучы кеше тәрбияләү булырга тиеш, минемчә. Шулай булмаса, кешелек яшәешенең – аның үткәненең дә, киләчәгенең дә мәгънәсе каламы соң?

Үзәк телевизион каналлар якынлашып килә торган финанс кризисы турында хәбәр иткәндә, мин, XXI гасыр баласы, рухи-әхлакый кризис хакында чаң сугам. Бәлки, уйланыр чак җиткәндер, Кешеләр?!

**Газетаның 27 нче октябрьдә (№33) басылып чыккан кроссвордның җаваплары:**

1. Александр; 2.Ленин; 3.Лингвистика; 4.Көнчыгыш; 5.Яковкин; 6.Лобачевский; 7.Попов; 8.Воскресение; 9.Кремль; 10.Универсиада; 11.Этнографик; 12.Дарелфөнүн; 13.Гафуров; 14.Чаллы; 15.Уникс; 16.Колонна; 17.Сәләхов; 18.Евтушенко; 19.Татарстан; 20.Гарәп; 21.Таба; 22.Унсигез; 23.Сессия; 24.Стипендия; 25.Толстой; 26.Казаным.

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.